Тема:

# Иярчен ия җөмләләр

# сәламәт

ы=ә



,,



,



,




,,

# сәламәтлек

О=Ә Ә=Е



,


,,


,,

л

,


# сәламәтләнү

Ы=

ә



,

И=А



,,,

Ч=Т



,

ЛӘНҮ

# Сәламәт

# Сәламәтлек

# Сәламәтләнү

# Сәламәт- (здоровый)-

исән;

исән-сау;

таза;

имин;

сау;

сау-сәламәт;

сихәт;

исән-имин

# Сәламәтлек-( здоровье, состояние здоровья)-

саулык; исәнлек;

сау-сәламәтлек; тазалык;

сихәтлек; исән-иминлек

# Сәламәтләнү-(выздоравливать, вылечиваться, поправляться)-

савыгу;
сихәтләнү;
төзәлү;
хәл керү;
тернәкләнү;
авырудан котылу

терелү;
тазару;
аякка басу;
хәлләнү;
арулану;

# Җөмләләр төзү

***Саулык- кешенең иң зур байлыгы ул.***

***Озак һәм бәхетле яшисе килсә, һәр кеше үзенең сихәтлеге турында кайгыртырга тиеш.***

***Меңләгән,миллионлаган кешеләр спортны яраталар, чөнки ул сәламәтлекне сакларга ярдәм итә.***

***Казанда тиздән бөтендөнья яшьләр универсиадасы үткәреләчәк, шуңа күрә бу мөмкинлекләр аеруча әһәмияткә ия.***

***Казанда быел бер-бер артлы төрле спорт чаралары уздырыла.***

Шунысы уңайлы: спорт түгәрәкләре мәктәптә эшләп тора.

Ялгызак мөнәсәбәтле сүз **шунысы**

Аналитик

[ ...шунысы]: ( ...).




Хәл ителде: ул иртәгә тренировкага бара.

Күренеп үк тора:”Рубин” футбол командасы җиңәчәк.

Көттерү интонациясе

Аналитик [… ]:(…).



Кем күнегүләрне тырышып өйрәнә, шул җиңә.
Кайсы спорт төре охшаса,шунысы белән шөгыльләнергә кирәк.

Парлы мөнәсәбәтле сүз ***кем-шул***
Парлы мөнәсәбәтле сүз ***кайсы-шунысы***

Аналитик (кем-шул),
(кайсы-шунысы)


2Бж.

1Ии Ж.

Күренә ки, спорт ярышлары киеренке үтәчәк.

Ияртүче теркәгеч ***ки***

Аналитик
[ ки],(…)



| Мисаллар | Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чара | Җөмлә төзелеше |
|---|---|---|
| Шунысы уңайлы: спорт түгәрәкләре мәктәптә эшләп тора. | Ялгызак мөнәсәбәтле сүз шунысы | Аналитик |
| Хәл ителде: ул иртәгә тренировкага бара.<br>Күренеп үк тора:”Рубин” футбол командасы җиңәчәк. | Көттерү интонациясе | Аналитик |
| Кем күнегүләрне тырышып өйрәнә,шул җиңә.<br>Кайсы спорт төре охшаса, шунысы белән шөгыльләнергә кирәк. | Парлы мөнәсәбәтле сүз кем-шул<br>Парлы мөнәсәбәтле сүз кайсы-шунысы | Аналитик |
| Күренә ки, спорт ярышлары киеренке үтәчәк. | Ияртүче теркәгеч ки | Аналитик |

# Нәтиҗә:

| Ия җөмләнең килү урыны | Соравы | Төре | Схемалары |
|---|---|---|---|
| | | аналитик | |
| Баш җөмлә нең иясе урынында килә.(выступают в роли подлежащего гл. пред-ия | Кем? Кто? Нәрсә? Что? | Көттерү паузасы, мөнәсәбәтле сүз, ки теркәгече (интон-ное предупреждение, относ. сл.союз ки) | [ ], баш җөмләне белдерә. ( ), иярчен җөмләне белдерә. |

# Нокталар урынына иярчен ия җөмләләр куеп дәфтәрләргә язарга.

1. *...., шул беренче урынны ала.*
2. *Күренеп тора: .... .*
3. *..., шулар ярышта җиңеп чыктылар.*

# Җөмләләрнең схемаларын төзергә.

1. ***Кем тырышып әзерләнә, шул ярышта җиңеп чыгар .***
2. ***Сизәм ки,син җиңәрсең .***
3. ***Күренеп тора : “Рубин” командасы җиңәчәк .***

# Өй эше:

1. “Мин спорт белән кызыксынам” инша язарга;

2. кагыйдә өйрәнергә.

# тест

- 1. Кушма җөмлә төрләре:
- а) гади җөмлә;
- ә) тезмә кушма җөмлә;
- б) иярченле кушма җөмлә;
- в) белмим .
- 2. Тезмә кушма җөмлә төрләре:
- а) теркәгечле кушма җөмлә;
- ә) иярченле кушма җөмлә;
- б) кушма җөмлә;
- в) теркәгечсез кушма җөмлә.
- 3. Аналитик бәйләүче чаралар:-
- а) парлы һәм ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр;
- ә) кушымчалар;
- б) аныклау һәм күтәрү интонациясе;
- в) ияртүче теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр.

- 4. Төзелеше буенча иярчен җөмләләрнең нинди төрләре бар?
- а) теркәгечле тезмә кушма;
- ә) синтетик;
- б) аналитик һәм синтетик;
- в) бүлүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнгән.
- 5. Рус телендә иярченле кушма җөмләләр бармы, алар ничек аталалар?
- а) сложносочиненные предложения;
- ә) простые, распространенные предложения;
- б) сложноподчиненные предложения;
- в) придаточные предложения.

- 6. Төзелеше ягыннан иярченле кушма җөмлә төрләренең кайсысы рус телендә юк?
- а) синтетик кушма җөмлә;
- ә) аналитик кушма җөмлә;
- б) аналитик һәм синтетик иярчен җөмлә.
- 7. Синтетик бәйләүче чаралар:
- а) кушымчалар;
- ә) парлы мөнәсәбәтле сүзләр;
- б) янәшә килү;
- в) бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр.

- 8. **Интонация бәйләүче чара булса, беренче җөмлә; *ки* теркәгече кергән җөмлә һәрвакыт беренче урында килә һәм**
- а) иярчен җөмлә;
- ә) баш җөмлә **була**.
- **9. Җөмләнең төрен билгелә.**
- ***Кемнәр тырышып әзерләнделәр, шулар ярышта җиңеп чыктылар.***
- а) гади җөмлә;
- ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә;
- б) иярченле кушма җөмлә;
- в) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә.

# Җаваплар

- 1. ә, б
- 2. а, в
- 3. а, б, в
- 4. б
- 5. б
- 6. а
- 7. а, б, в
- 8. ә
- 9. б

# Укучылар, булдырдыгыз!!!

Кәефләрегез ничек?
Сәламәт булыгыз!

